ГЛАВА
КУТЛУ-БУКАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422665, с.Кутлу-Букаш.
ул.Советская , дом 32

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
КОТЛЫ БӨКӘШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
422665, Котлы Бөкәш авылы
Совет урамы, 32 йорт

Тел.: (84361) 31521, факс: (84361) 31642, e-mail: Kbuk.Rs@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның 29 октябре Котлы Бөкәш авылы № 2

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең Тәберде Чаллысы авыл торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Котлы Бөкәш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең Тәберде Чаллысы авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2024 елның 29 октябрендә 10 сәг. 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү территориаль билге буенча гамәлгә ашырылуын расларга.

3. Гражданнар җыены каравына куела торган сорауны расларга:

Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең Тәберде Чаллысы авылы торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән, махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, көндезге формада белем алучы студентлардан , тумыштан инвалид булган, 1 группа инвалид, баласыз япа-ялгыз яшәүче яшьләре 80 нән узган өлкән яшьтәге кешеләрдән кала һәм аларның гомуми саны җирлектә яшәүчеләрнең 30% тан артмаган очракта, 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм

тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- торак пункт территориясен төзекләндерү;
- урам утларының яктырту системасына хезмәт күрсәтү;
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау;
- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү;
- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;
- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту.

“ЯКЛЫЙМ” “КАРШЫ”

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Котлы Бөкәш авылы, Совет урамы, 32 йорт; Тәберде Чаллысы авылы, Совет урамы, 34 йорт; Мәмли Казак Чаллысы авылы, Үзәк урам, 29 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда.

5. Карар басылып чыккан (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Котлы Бөкәш авыл җирлеге башлыгы Г.Г. Нәҗипов